Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Манзарас авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2022 елның 11 ноябре                                                                 № 43

Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 27 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Манзарас авылы, Яшьләр урамы, 18а йорты адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 27 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Манзарас авылы, Яшьләр урамы, 18а йорты адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2022 елның 27 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Манзарас авылы, Яшьләр урамы, 18а йорты адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. 2022 елның 27 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Манзарас авылы, Яшьләр урамы, 18а йорты адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген аеруны (территориаль, вакытлы яки башка төрле билге буенча) сайлау тәртибе муниципаль берәмлек башлыгының гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарында күрсәтелә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,

көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокլы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Манзарас авылында урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), бишенче линияне төзү, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Манзарас авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылына янгын гидрантлары һәм комплектлау җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын ремонтлау, янгын гидрантларын комплектлау, смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылы территориясен төзекләндерү;

- Манзарас авылы юлларына асфальт җәю, торбалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, экспертиза үткәрү;

- Манзарас авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау (торбаларны алыштыру, материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Яңгыр канауларын һәм канализацияләрен урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Физкультура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, спорт чараларын уздыруны оештыру: булган яссылык спорт корылмаларын карап тоту, тренировкалар оештыру, спорт чараларын әзерләү һәм уздыру өчен белгеч тоту;

- Манзарас авылына янгын гидрантлары һәм комплектлау җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Парковка урыннарын төзү һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылында тротуарлар төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылы Мәдәният йортын карап тоту, Мәдәният йорты котельнаясын ремонтлау, Мәдәният йорты залы өчен кәнәфиләр сатып алу .

«РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хәбибуллина